# Ылыслы әкият

Дусларның әкияти маҗаралары

# Хвойная сказка

Сказочные приключения друзей



# Ылыслы әкият

## Дусларның әкияти маҗаралары

www.хвойнаясказка.рф

**УЙНА, ҖЫРЛА, РӘСЕМ ЯСА!**

хвойнаясказка.рф сайтыннан Android, iOS өчен каралган түләүсез «Хвойная сказка» мобиль кушымтасын йөкләргә мөмкин. Анда түбәндәге материаллар урын алган:

- **Балалар өчен күңелле интерактив үстерешле 8 уен.**
  Аларны уйнап, бала калдыкларны дөрес итеп төрләргә аерырга һәм әйләнә-тирә мохиткә сакчыл карарга өйрәнәчәк.
- **Караоке функциясе булган, табигать турында үзенчәлекле 6 балалар җыры.**
  Аларны гаилә белән җыелып җырлау күңеллерәк.
- **Белем бирә торган 4 балалар буягычы.**
  Алар табигатьтә үзеңне дөрес тотуның төп кагыйдәләре белән таныштырачак.

**ЭКОЛОГИК КҮЗӘТҮЛӘР КӨНДӘЛЕГЕ**

хвойнаясказка.рф сайтында кызыклы биремнәр һәм фактларны үз эченә алган күзәтүләр көндәлеген йөкләргә була. Ул файдалы экологик гадәтләр булдырырга, кулланылган материаллардан кирәкле әйберләр һәм матур эшләнмәләр ясарга өйрәнергә ярдәм итәчәк. Ә көндәлекнең уртасында сюрприз яшерелгән!



# Хвойная сказка

Сказочные приключения друзей

www.хвойнаясказка.рф

## ИГРАЙ, ПОЙ, РИСУЙ!

На сайте хвойнаясказка.рф можно скачать бесплатное мобильное приложение для Android и iOS «Хвойная сказка», в котором есть:

- **8 весёлых интерактивных развивающих детских игр,** играя в которые ребёнок научится правильно сортировать отходы и бережнее относиться к окружающей среде.
- **6 оригинальных детских песен с функцией караоке** о природе, которые веселее петь всей семьёй.
- **4 обучающие раскраски для детей,** которые познакомят с основными правилами безопасного поведения на природе.




## ЭКОЛОГИЧЕСКИЙ ДНЕВНИК НАБЛЮДЕНИЙ

На сайте хвойнаясказка.рф можно скачать дневник наблюдений с заданиями и интересными фактами, который поможет приобрести полезные экологические привычки, научиться делать нужные вещи и красивые поделки из использованных материалов. А в середине дневника спрятан сюрприз!

УДК 821.512.145-343.4
ББК 83.84(2=632.3)6-45
Ы37



ЭМОЦИОНАЛЬНЫЙ ИНТЕЛЛЕКТ
ТАТАРСКОЕ ДЕТСКОЕ ИЗДАТЕЛЬСТВО • ТАТАР БАЛАЛАР НӘШРИЯТЫ

ISBN 978-5-6043753-6-5

© Татарское детское издательство, 2021



# Ылыслы әкият

Дусларның әкияти маҗаралары

# Хвойная сказка

Сказочные приключения друзей

www.хвойнаясказка.рф

Казань
2021

## КАДЕРЛЕ ДУСТЫМ!

Татарстанның табигате гаҗәеп бай һәм күптөрле. Имәнлекләр, яфраклы һәм ылыслы урманнар, кырлар һәм болыннар, елгалар һәм күлләр, аларда яшәүче җәнлек-җанварлар, кош-кортлар һәм балыклар – безнең байлыгыбыз. Аларны үстерү, арттыру һәм саклау бик мөһим.

Табигатьне ярату безне миһербанлырак итә, безгә көч һәм куәт бирә.

Табигатьнең чын дусты һәм яклаучысы бул. Үз республикаңны, үз Ватаныңны сакла.

Татарстан Республикасы Президенты
Р.Н. Миңнеханов

## ДОРОГОЙ ДРУГ!

Природа Татарстана удивительна и многообразна. Дубравы и рощи, поля и луга, реки и озёра, их обитатели – это наше богатство, которое важно беречь и приумножать.

Любовь к природе делает нас добрее, даёт нам силу и энергию.

Будь защитником и другом природы. Береги свою республику, свою Родину.

Президент Республики Татарстан
Р.Н. Минниханов



# ИСӘНМЕ, ЯШЬ ТАТАРСТАНЛЫ!

Без сине «Ылыслы әкият» сәхифәләре буйлап сәяхәткә чакырабыз.

Татарстан – безнең ватаныбыз, ә табигать – уртак йортыбыз. Без әлеге йортның хуҗалары һәм сакчылары. Ул синең өеңнән, ишегалдыңнан, шәһәреңнән башлана. Үз өең чиста, матур, якты булсын өчен ничек тырышсаң, туган як табигате турында да шулай ук кайгыртырга кирәк.

Бу китап ярдәмендә син аның байлыкларын сакларга, җир-суыбыз турында кайгыртырга өйрәнерсең. Табигатьне пычратмас өчен чүп-чарны кая куярга кирәклегенә төшенерсең. Калдыкларның күп төрен кабат эшкәртүгә тапшырырга була, ә алардан кулланырга яраклы яңа әйберләр җитештерәчәкләр. Синең белән бергә үсәчәк үз агачыңны да утырта алачаксың. Ә аның янәшәсендә синең дусларың утырткан агачлар үсәр, һәм туган ягыбыз – Татарстан тагын да матурланыр, баерак булыр!



# ЗДРАВСТВУЙ, ЮНЫЙ ТАТАРСТАНЕЦ!

Приглашаем тебя в увлекательное путешествие по страницам «Хвойной сказки».

Татарстан – наша родина, а родная природа – наш общий дом. Мы хозяева и главные защитники этого дома. Он начинается с дома, в котором ты живёшь, с твоего двора, города. Как ты заботишься о своём доме, следишь за тем, чтобы в нём было чисто, уютно и светло, так нужно заботиться о природе родного края.

С помощью этой книги ты научишься беречь её богатства, заботиться о её чистоте. Ты узнаешь о том, как правильно поступать с мусором, чтобы не загрязнять природу. Ведь многие виды отходов можно сдавать на переработку, где из них сделают полезные вещи, которые снова можно использовать. А ещё ты сможешь своими руками посадить собственное дерево, которое будет расти вместе с тобой. Рядом появятся деревья, посаженные твоими друзьями, и наш дом Татарстан станет ещё прекраснее и богаче!



# ХӨРМӘТЛЕ ӘТИ-ӘНИЛӘР!

Сезнең алдыгызда үзенчәлекле китап. «Ылыслы әкият» аша сезнең балагыз экологиягә кагылышлы беренче мәгълүматка ия булыр, табигатьне сакларга, үсемлекләр һәм хайваннар турында кайгыртырга, табигать байлыкларына сакчыл карарга өйрәнер.

Китап балалар да, өлкәннәр дә кызыксынып укырлык итеп эшләнде. Әкияттән, ягъни табигатьтә суның ничек барлыкка килүе, агачларны саклауның мөһимлеге, чүп-чарны дөрес итеп аерым җыю хакында сөйләүче геройларның маҗараларыннан тыш, китапта кызыклы фактлар, Татарстан табигате турында мәгълүматлар, экологик белешмәләр, танып белүгә ярдәм итүче һәртөрле биремнәр бар. Смартфон яки планшет камерасын китап битләрендә урнашкан QR-кодларга юнәлтегез һәм сез www.хвойнаясказка.рф сайтына эләгерсез. Биредә Android һәм iOS өчен мобиль кушымта йөкләтергә мөмкин. Анда караоке-җырлар, буяр өчен рәсемнәр, уеннар бар. Алар ярдәмендә бала табигатьне кадерләргә һәм яратырга өйрәнер.

Беренче сыйныф укучысына теге яки бу табигать күренешләрен аңлатып биргәндә, сезнең тәҗрибә һәм белемегез ярдәм итәр. Табигать белән танышканда бала барысын да аңлап бетерә алмаска мөмкин. Нәкъ менә сез баланы әйләнә-тирәбезнең матурлыгын, нәфислеген күрергә, планетабыз чүп-чар базына әйләнмәсен өчен, чүп-чарларны утильләштерүгә җитди карарга өйрәтә һәм аңарда табигатькә, туган җиребезгә мәхәббәт, җаваплылык хисен тәрбияли аласыз. Ә иң мөһиме – балагызның киләчәге яхшырак булсын өчен, бүген ниләр эшләргә мөмкин икәнлеген шәхси үрнәгегездә күрсәтәсез.

# УВАЖАЕМЫЕ РОДИТЕЛИ!

Перед вами особенная книга. «Хвойная сказка» – это занимательное издание, с которым ваш ребёнок получит первое представление об экологии, научится беречь природу, заботиться о животных и растениях, экономить ресурсы.


Книга построена так, чтобы её было интересно читать и детям, и взрослым. Кроме сказки – удивительной истории о маленьких добродушных героях, которые расскажут, откуда берётся вода в природе, как важно беречь деревья, как правильно сортировать мусор, в книге есть интересные факты, занимательная информация о природе Татарстана, экопамятки, разнообразные познавательные задания. Наведите камеру смартфона или планшета на QR-коды, расположенные на страницах книги, и вы попадёте на сайт www.хвойнаясказка.рф, где можно скачать мобильное приложение для Android и iOS с песнями-караоке, раскрасками, играми, с помощью которых ребёнок научится ценить и любить живую природу.

Ваш опыт и знания пригодятся, когда вы будете объяснять своему первокласснику то или иное явление в природе. Ведь, изучая природу, дети могут правильно понять далеко не всё. Именно вы можете воспитать в ребёнке любовь к природе, родной земле, показать, как прекрасен и хрупок наш мир, привить ребёнку чувство ответственности за всё, что его окружает, научить осознанному отношению к утилизации мусора, чтобы наша планета не превратилась в огромную мусорную свалку. А главное – показать на собственном примере, что можно сделать сегодня, чтобы будущее вашего ребёнка стало лучше.

Бик матур бер илдә, куе урман читендә зур һәм бик юан агач үскән. Аның кабарып торган бер күркәсендә кечкенә генә Орлык яшәгән.

Көннәрнең берендә, дуслары уңайлы күркә-өйләрендә тәмле төшләр күреп йоклап ятканда, Орлык йоклап китә алмый. Ул ерак илләргә сәфәргә чыгу турында хыяллана.

– Их, мин дөнья буйлап сәяхәт итәр идем. Кошлар җыры аша таныш булган чиста елгаларны, чиксез болыннарны, гаҗәеп чәчәкләрне күрер идем! – дип уйлый ул.



В одной прекрасной стране, на краю густого леса росло большое могучее дерево. В одной из его пушистых шишек жила-была маленькая Семечка.

Однажды, когда подружки-семечки уже сладко спали в своём уютном домике-шишке, Семечке не спалось. Она мечтала о путешествии в далёкие края.

– Ах, как бы я хотела увидеть мир – чистые реки, бескрайние луга, удивительные цветы, о которых так сладко поют птицы! – думала Семечка.



## Ә СИН БЕЛӘСЕҢМЕ? | А ЗНАЕШЬ ЛИ ТЫ?

Көнчыгыш Европадагы иң зур елгалар – Идел һәм Чулман Татарстан территориясе буйлап ага.


В Татарстане протекают самые крупные реки в Восточной Европе – Волга и Кама.




## БИРЕМ | ЗАДАНИЕ

Балыкка Иделдән Чулманга кучәргә ярдәм ит.

Помоги рыбке добраться из Волги в Каму.




ИНТЕРАКТИВНЫЕ ИГРЫ


## Ә СИН БЕЛӘСЕҢМЕ? | А ЗНАЕШЬ ЛИ ТЫ?

Безнең планетада су бик күп, шунлыктан, космонавтларның әйтүләренә караганда, космостан ул зәңгәр булып күренә.

Җирдәге су өслеге коры җир өслегеннән 3 тапкырга артыграк. Шуңа күрә безнең планетаны Җир дип түгел, Су дип атасаң, дөресрәк булыр иде кебек.

На нашей планете много воды, поэтому, как говорят космонавты, из космоса она кажется голубой.


Поверхность воды на Земле в 3 раза больше поверхности суши. Поэтому, наверное, правильнее было бы называть нашу планету не Земля, а Вода.




## ФАКТ | ФАКТ

Су – табигатьтә берьюлы 3 халәттә була ала торган бердәнбер матдә.

Вода – единственное вещество, которое существует в природе сразу в 3-х состояниях.








Шулай бервакыт агач яныннан үзенең пәрәвезе белән Үрмәкүч үтеп бара иде.

– Үрмәкүчкәй, – дип эндәште аңа Орлык. – Кая китеп барышың?

– Өйгә, – дип җавап бирде аңа Үрмәкүч.

– Мине дә үзең белән ал әле! – дип үтенде Орлык.

– Курыкмасаң, очыйк әйдә, – дип җавап бирде аңа Үрмәкүч.

Орлык яшел үзән, биек ярларын куе урман каплаган көмештәй саф сулы елга өстеннән очты. Мондый матурлыкны күргәне юк иде әле аның. «Нинди гүзәл безнең яклар!» – дип уйлады ул.

Как-то раз мимо дерева пролетал Паучок на своей паутинке.

– Паучок! – позвала его Семечка. – Куда ты летишь?

– Лечу домой, – ответил Паучок.

– Возьми и меня с собой! – попросила его Семечка.

– Полетели, если не боишься, – ответил Паучок.

Семечка летела над зелёной долиной, по которой, блестя на солнце серебряными искорками, текла река, над высоким берегом, поросшим лесом. Никогда ещё не видела она такой красоты и думала, в каком прекрасном краю живёт!

– Мин кайтып җиттем, – диде Үрмәкүч, җиргә төшкәч. – Тиздән яңгыр явачак. Ышык урынга керсәң, яхшырак булыр, – дип, ул үләннәр арасына кереп китте, Орлык үзе генә калды.

– Синең исемең ничек? – дип сорады шунда кемдер.

– Орлык. Ә син кем?

– Тамчы мин, – диде яңа танышы.

– Каян килеп чыктың син? – дип гаҗәпләнде Орлык.

– Ну, вот я и дома, – сказал Паучок, когда они оказались на земле. – Скоро пойдёт дождь. Лучше бы тебе спрятаться, – и, попрощавшись, скрылся в траве, а Семечка осталась одна.

– Как тебя зовут, – послышалось рядом.

– Семечка. А тебя?

– А меня Капелька, – ответила незнакомка.


– Откуда ты взялась? – удивилась Семечка.






## Ә СИН БЕЛӘСЕҢМЕ? | А ЗНАЕШЬ ЛИ ТЫ?

Фил тәүлегенә 9 чиләк су эчә.
За 1 день слон выпивает 9 вёдер воды.




## БИРЕМ | ЗАДАНИЕ

Рәсемнәрне ясап бетер һәм буя.
Дорисуй и раскрась картинки.



ИНТЕРАКТИВНАЯ
РАСКРАСКА

## Ә СИН БЕЛӘСЕҢМЕ? | А ЗНАЕШЬ ЛИ ТЫ?

Кайнар су салкынына караганда тизрәк ката. Һәм ни өчен шулай булуын беркем дә белми.


Горячая вода замерзает быстрее, чем холодная. И никто не знает, почему так происходит.




## ФАКТ | ФАКТ

Без эчәргә яраклы суның бик аз өлешен генә куллана алабыз. Күп өлеше бозлыкларга туры килә.

Из всей питьевой воды, какая есть на Земле, нам доступна лишь малая её часть. Большая часть заморожена в ледниках.






– Болыттан, яңгыр Тамчысы мин. Элек океанда яшәгән идем. Кояш бик нык җылыткач, мин бик кечкенә һәм җиңел парга әйләндем. Аннан биеккә-биеккә күтәрелдем һәм, башка тамчы дусларым белән берләшеп, без болытка әверелдек. Өстә бик салкын иде. Күбәйгәч, яңгыр булып яудык.

Мин сәяхәт итәргә яратам. Шунлыктан тиздән җир асты сулыкларына, ә аннан кабат океанга эләгәчәкмен. Ә кышын мин кар бөртегенә әверелә алам!

– Из тучки. Я дождевая Капелька. А раньше я жила в океане. Однажды солнышко пригрело, и я превратилась в пар – стала очень маленькой и лёгкой. Я поднималась всё выше и вместе с подружками-капельками стала облачком.

Наверху нам было холодно. И когда нас стало много, мы упали с неба дождиком.

Люблю путешествовать, поэтому скоро через подземные реки я попаду в речку, а потом снова в океан. А зимой я могу превратиться в снежинку!

– Гади генә түгел, чиста су тамчысы мин!

Су бар тереклеккә дә кирәк! Кешеләргә дә, хайваннарга да, үсемлекләргә дә! Су булмаса, җир йөзендәге бар тереклек һәлак булыр иде. Күрәсеңме, яңгырдан соң тирә-юнь яшәреп китте. Хәтта син дә үсеп киттең.

– Нинди бәхетле син, Тамчыкай! Күп җирләрдә булып, күп нәрсәләр күргәнсең син. Мин бик тә сәяхәт кылу турында хыялланам!


– Мин сиңа ярдәм итәм! Ахирәтем Җил сине кая телисең, шунда илтер.

– Я капелька не простая, а из чистой воды!

Вода нужна всем! И людям, и животным, и растениям! Ты знаешь, что без воды на земле всё бы погибло? Вот видишь, дождик полил, и всё вокруг выросло. И даже ты подросла.

– Какая ты счастливая, Капелька! Ты везде побывала, много видела. Я так мечтаю отправиться в путешествие!


– Я тебе помогу! Мой приятель Ветерок отнесёт тебя куда хочешь.



## Ә СИН БЕЛӘСЕҢМЕ? | А ЗНАЕШЬ ЛИ ТЫ?

Хайваннарда су бар!
Иң күбе медузаларның аурелия төрендә – 99 % һәм бакада – 77 %.

В животных есть вода!
Больше всего воды в медузе аурелии – 99 % и лягушке – 77 %.




Үсемлекләр арасында су иң күп булганнары.
Рекордсмены по содержанию воды среди растений.

## БИРЕМ | ЗАДАНИЕ

Су нәрсәләргә әверелә ала?
Дөрес дип исәпләгән рәсемнәрне билгелә.

Во что может превратиться вода?
Отметь правильные изображения.



ИНТЕРАКТИВНЫЕ
ИГРЫ

## ФАКТ | ФАКТ

# В Татарстане

**6914** рек

**8000** озёр

Самые крупные реки:

- Волга
- Кама
- Вятка
- Белая
- Ик
- Свияга
- Большой Черемшан
- Шешма

Самые крупные озёра:

- Средний Кабан
- Ковалинское
- Архиерейское
- Нижний Кабан
- Лебяжье
- Подборное
- Раифское
- Ильинское




## Ә СИН БЕЛӘСЕҢМЕ? | А ЗНАЕШЬ ЛИ ТЫ?

Татарстандагы иң чиста сулы елга – Лубянка (Кукмара районы). Анда сирәк очрый һәм бары тик чиста сулыкларда гына яши ала торган хариус һәм елга зәңгеләсе балыклары бар.

Самой чистой рекой Татарстана считается Лубянка (Кукморский район). В ней обитают редкие рыбы – хариус и речной гольян, которые живут только в чистой воде.

Самые распространённые виды рыб в Татарстане:

- лещ
- щука
- судак
- окунь
- карась





– Сәлам! Кем чакырды мине?

– Сәлам, Җилкәй! Таныш бул, бу минем дустым Орлык. Әйдә, аңа безнең гүзәл җиребезне күрсәтәбез!

– Бик шатланып! – дип җавап бирде Җил.

Тамчы белән Орлык кулга-кул тотыныштылар, һәм Җил аларны болытларга алып менеп китте.

– Ялтырап күренүче әйбер нәрсә ул? – дип гаҗәпләнеп сорады Орлык.

– Елгалар һәм күлләр, – дип елмайды Тамчы.

– Безнең төбәктә елга-күлләр күп! – дип өстәде Җил.

– Привет! Кто меня звал?

– Здравствуй, Ветерок! Знакомься, это моя подружка Семечка. Давай поможем ей увидеть нашу прекрасную землю!

– С удовольствием! – ответил Ветерок.

Капелька с Семечкой взялись за руки, и Ветерок легонько поднял их к самому облачку.

– Что это так блестит? – удивилась Семечка.

– Это реки и озёра, – улыбнулась Капелька.

– В нашем краю много рек и озёр! – сказал Ветерок.

– Идел, Чулман, Нократ, Зөя – безнең төбәктәге иң матур һәм зур елгалар. Минем чиста сулы Зәңгәр күлдән, Каракүлдән, Кабан, Аккош, Раифа күлләреннән булган тамчы дусларым бар, – дип мактанды Тамчы.

– Җирдә су бик күп! Тик шул ук вакытта бик аз да, – дип авыр сулап куйды Җил.

– Бер үк вакытта күп тә, аз да буламыни? – дип аптырады Орлык.



– Самые красивые и большие реки в нашем краю – Волга, Кама, Вятка и Свияга. Мои лучшие подружки – капельки из самого чистого Голубого озера, озёр Кара-Куль, Кабан, Лебяжьего и Раифского, – похвалилась Капелька.

– Воды на земле очень много, куда ни посмотри! Но всё же её очень мало, – вздохнул Ветерок.

– Разве так бывает – много, но мало? – удивилась Семечка.



## Ә СИН БЕЛӘСЕҢМЕ? | А ЗНАЕШЬ ЛИ ТЫ?

Синең үзеңдә, әтиеңдә һәм әниеңдә дә су бар!
В тебе, в твоих маме и папе тоже есть вода!




## ФАКТ | ФАКТ

Су кешеләргә генә кирәкле матдә түгел, аны хайваннар да, бөҗәкләр дә, үсемлекләр дә, урман һәм кырлар да эчә. Хәтта завод-фабрикалар да сусыз эшли алмый.

Вода нужна не только людям. Воду пьют животные, насекомые и растения, поля и леса. Даже заводы и фабрики не могут работать без воды.



1 башак бодай үстерү өчен, 2 литр тирәсе су кирәк. 1 альбом бите җитештерү өчен, 10 литр су кирәк. Ә ирләр күлмәге һәм чалбар җитештергәндә 10 мең литр яки 1 мең чиләк су тотыла.
**СУНЫ САКЛАГЫЗ!**

Чтобы вырастить 1 колосок пшеницы, нужно почти 2 литра воды. Чтобы сделать 1 альбомный лист, нужно 10 литров воды. А для изготовления рубашки и брюк нужно потратить 10 тысяч литров, или 1 тысячу вёдер воды.
**БЕРЕГИТЕ ВОДУ!**



ПЕСЕНКА
КАРАОКЕ

## ФАКТ | ФАКТ

Төче су – эчәргә яраклы су ул.
Пресная вода – это вода, которую можно пить.




## БИРЕМ | ЗАДАНИЕ

Санап кара әле, син көненә ничә мәртәбә су белән очрашасың?
Посчитай, сколько раз в день ты встречаешься с водой.

1 ______________________________

2 ______________________________

3 ______________________________

4 ______________________________

5 ______________________________


6 ______________________________

7 ______________________________

8 ______________________________

9 ______________________________

10 ______________________________



– Табигатьтәге барлык суларны да эчеп булмый. Чиста төче сулар гына яшәеш өчен яраклы. Ә ул бик аз, – диде Тамчы.

– Суны берни белән дә алыштырып булмый, – дип килеште Җил. – Су – Җирдәге иң зур байлык, шуңа күрә аны сакларга кирәк!

– Беләсеңме, Орлык, чиста су торган саен кими бара, – дип авыр сулап куйды Тамчы. – Ә пычрак сулар бар тереклеккә зыян сала.

– Пычрак сулар да буламыни? – дип аптырашта калды Орлык.

– Не всю воду, которая есть в природе, можно пить. Для жизни подходит только чистая пресная вода. А её очень мало, – сказала Капелька.

– Воду ничем не заменишь, – согласился Ветерок. – Вода – это главное богатство на Земле, поэтому её нужно беречь!

– Знаешь, Семечка, чистой воды становится всё меньше, – вздохнула Капелька. – А от грязной воды страдает всё живое.

– А что, вода бывает грязная? – удивилась Семечка.

– Елга һәм күлләр төче сулы, тик алар бик үк чиста түгел. Аларга туфрак, чыбык-чабык, яфраклар төшә.

Ә кайчакта аларны кешеләр пычрата. Завод һәм фабрикалар бик күп су куллана һәм бер үк вакытта аны сәнәгать калдыклары белән пычрата.

Кайбер кешеләр үзләренең табигатьнең бер кисәге булуын аңламый. Алар агачларны сындыра, чәчәкләрне өзә, җиргә җир-суларны агулап торучы чүпләр ташлый. Шул сәбәпле хайваннар, кошлар һәм кешеләр үзләре дә авырыйлар, – диде Тамчы моңсу гына.

– Вода в реках и озёрах пресная, но не совсем чистая. В неё попадают частички земли, веточки, листья.

А иногда её загрязняют люди. Их заводы и фабрики используют много воды и одновременно загрязняют её отходами.


Некоторые люди не понимают, что они – часть природы. Они ломают деревья, рвут цветы, оставляют мусор, который отравляет землю и воду. От этого болеют животные, птицы и сами люди, – грустно сказала Капелька.



## Ә СИН БЕЛӘСЕҢМЕ? | А ЗНАЕШЬ ЛИ ТЫ?


Пычранган җир асты сулары чистарганчы берничә мең ел үтә.

Загрязнённые подземные воды очищаются в течение нескольких тысячелетий.








## ТӘҖРИБӘ ЯСА! ПРОВЕДИ ИССЛЕДОВАНИЕ!



1. Ике стаканга су сал.
   Налей в два стакана воду.



2. Бер стаканга азык буягыч яки язу карасы сал.
   В один стакан добавь пищевой краситель или чернила.



3. Ике стаканга да берәр тармак сельдерей салып куй.
   Поставь в оба стакана по веточке сельдерея.

Икенче көнне алар белән ни булганын кара. Ничек уйлыйсың, ни өчен шулай булган? Фикереңне яз.


Что стало с веточками на следующий день? Как ты думаешь, почему это произошло? Напиши.

ИНТЕРАКТИВНЫЕ ИГРЫ

## Ә СИН БЕЛӘСЕҢМЕ? | А ЗНАЕШЬ ЛИ ТЫ?

Пычрак суда зарарлы бактерияләр үрчи. Алар гади күзгә күренмәсәләр дә, авырулар китереп чыгарып, безнең сәламәтлегебезгә зыян китерә.

В грязной воде живут вредные бактерии, которые не видны, но причиняют вред нашему здоровью, вызывая болезни.



## БИРЕМ | ЗАДАНИЕ

Су – һәр тере зат өчен яшәеш нигезе һәм табигый байлык.
Су турындагы мәкаль һәм әйтемнәрнең өлешләрен уклар белән тоташтыр.

Вода – это основа жизни всех живых существ и настоящее природное богатство.
Собери пословицы и поговорки о воде, соединив их части стрелками.

| | |
|---|---|
| Яткан таш астыннан<br>Под лежачий камень | суга кермә.<br>не суйся в воду. |
| Судан тын,<br>Тише воды, | су да акмый.<br>вода не течёт. |
| Ерып чыгарлык булмаса,<br>Не зная броду, | су ташып булмый.<br>не удержишь. |
| Ипи дә су –<br>Хлеб да вода – | үләннән түбән.<br>ниже травы. |
| Иләк белән<br>Воду в решете | үзенә юл таба.<br>себе путь найдёт. |
| Су һәрвакыт<br>Вода всегда | ир-егетләр азыгы шул.<br>молодецкая еда. |






– Борчылма, Тамчы! Мин күп җирләрдә булам һәм табигатьне яратучы, аның чисталыгы өчен көрәшүче кешеләрне күп очратам, – диде Җил.

– Андый кешеләрнең булуы бик яхшы, – дип елмайды Орлык.

– Карагыз әле! Көзге болыт йөзеп бара. Күптәнге танышым! – дип шатланды Җил.

– Ю-юлга! – дип гүләде Болыт. – Тиздән көз җитә. Ю-юлга!

– Чынлап та, миңа китәргә вакыт. Мин бит җылы җил.

– Миңа да юлга кузгалырга вакыт, – дип көрсенде Тамчы.

– Не печалься, Капелька! Я всюду летаю и вижу много людей, которые любят природу и заботятся о её чистоте, – сказал Ветерок.

– Как хорошо, что есть такие люди, – улыбнулась Семечка.

– Смотрите! Осенняя Туча летит. Давняя знакомая! – обрадовался Ветерок.

– В пу-у-уть! – прогудела Туча. – Скоро осень. В пу-у-уть!

– И правда, пора улетать. Ведь я тёплый ветерок.

– Мне тоже нужно отправляться в дорогу, – вздохнула Капелька.

Җил Орлык белән Тамчыны әләктереп алды да, алар бергәләп аланга төштеләр.

– Искиткеч сәяхәт булды бу! – диде Орлык.

– Орлыккай, сиңа кыш җиткәнче урнашып калырга кирәк, – диде Тамчы. – Шушы аланда кал, ә яз җиткәч, без кабат очрашырбыз.

– Язга кадәр, – дип, Җил Орлыкны яфрак белән каплап куйды.

– Тыныч йокы, – диде Тамчы.

– Күрешкәнчегә кадәр, дусларым, – дип җавап бирде аларга Орлык һәм татлы йокыга талды.

Ветерок подхватил Семечку и Капельку, и они вместе опустились на полянку.


– Какое чудесное путешествие получилось! – восхищённо сказала Семечка.

– Семечка, тебе нужно устраиваться на зиму, – сказала Капелька. – Оставайся на этой полянке, а весной мы снова встретимся.

– До весны, – сказал Ветерок и заботливо укрыл Семечку листочком.

– Счастливых снов, – сказала Капелька.

– До встречи, друзья, – ответила Семечка и сладко заснула.



## ТӘҖРИБӘ | ЭКСПЕРИМЕНТ


### САЛАВАТ КҮПЕРЕ ЯСА!
### СДЕЛАЙ РАДУГУ!

1. Көзгене, бераз авыштырып, суга урнаштыр.
Поставь зеркало в воду под небольшим углом.

2. Көзге белән кояш нурларын тотып, диварга юнәлдер.
Поймай зеркалом солнечный луч и направь на стену.

3. Көзгене диварда салават күпере барлыкка килгәнче боргала.
Поворачивай зеркало, пока на стене не появится радуга.






## ФАКТ | ФАКТ

Бер кеше елына уртача 800 литр су эчә.
Бу 3 мең стаканнан артык дигән сүз.

Один человек в среднем выпивает 800 литров воды в год. Это больше 3-х тысяч стаканов!

ИНТЕРАКТИВНАЯ РАСКРАСКА

## СУ – ТАБИГАТЬНЕҢ БӘЯЛӘП БЕТЕРГЕСЕЗ БҮЛӘГЕ

СУГА САКЧЫЛ КАРАШ – ТОРМЫШНЫ ҺӘМ ӘЙЛӘНӘ-ТИРӘДӘГЕ МАТУРЛЫКНЫ САКЛАУ УЛ!

СИН ТАБИГАТЬКӘ НИЧЕК ЯРДӘМ ИТӘ АЛАСЫҢ

Ваннада түгел, ә душта юын!



Принимай душ вместо ванны!

Жырны йөкләт һәм кушылып жырла, жыр тәмамланганчы юынырга өлгер, һәм син бер елга 2 зур янгын сүндерү машинасына сыешлы суны саклап калырсың.




Скачай песенку и попробуй умыться за то время, пока её поёшь, и за год сэкономишь воду, которой можно заполнить 2 огромные цистерны пожарных машин.

Кулларыңны суны аз гына агызып ю!



Мой руки под тонкой струёй!

Жиләк-жимешләрне агып торган суда түгел, махсус савытта ю!



Мой фрукты и овощи в специальной посуде, а не под проточной водой!

Аэратор ярдәмендә су 2 тапкыр азрак тотыла.




Насадка-аэратор помогает экономить воду в 2 раза.

Унитазга чүп салма!



Не выкидывай мусор в унитаз!

# ВОДА – БЕСЦЕННЫЙ ДАР ПРИРОДЫ

БЕРЕЧЬ ВОДУ – ЗНАЧИТ БЕРЕЧЬ ЖИЗНЬ И КРАСОТУ ОКРУЖАЮЩЕГО МИРА!

КАК ТЫ МОЖЕШЬ ПОМОЧЬ ПРИРОДЕ

Суны бушка агызма.
Су кирәк булмаганда, кранны яп.




Старайся не тратить воду впустую.
Закрывай кран, когда вода тебе не нужна.

Краннарның төзеклеген тикшереп тор.
Краннан тамып торганда елына 8 мең стакан су әрәмгә ага.



Следи за тем, чтобы краны были исправными.
Из капающего крана вытекает
8 тысяч стаканов питьевой воды в год.

Әгәр синең гаиләң краннан килгән суның биштән бер өлешен генә экономияләсә дә, бер елга сез футбол кыры зурлыгындагы һәм кеше буе тирәнлегендәге чиста сулы күлне саклап калган кебек буласыз.





Если твоя семья сэкономит хотя бы одну пятую часть используемой водопроводной воды, то за год вы сбережёте целое озеро чистой воды размером с футбольное поле и глубиной с человеческий рост!

## Ә СИН БЕЛӘСЕҢМЕ? | А ЗНАЕШЬ ЛИ ТЫ?

Һава – табигый бакчачы. Җил орлыкларны аларның өйләреннән еракка алып китә. Шул рәвешле яңа урманнар һәм болыннар барлыкка килә.

Воздух – природный садовник. Ветер подбирает семена и переносит далеко от их дома. Так появляются новые леса и луга.



## ФАКТ | ФАКТ

Иң күп чиста һава Себер тайгаларында һәм Амазонка урманнарында бүленеп чыга.*

В мире растений больше всего чистого воздуха вырабатывают сибирская тайга и леса Амазонки.*




* Россиянең Азия өлешендәге мәңге яшел Себер тайгасы – планетадагы иң зур урман. Себер тайгасын һәм Көньяк Америкада урнашкан дөньядагы иң зур тропик Амазонка урманын «планетаның үпкәсе» дип атыйлар, чөнки алар без сулый торган һаваны чистарта һәм бик күп кислород бүлеп чыгара.

* Сибирская тайга – это самый большой вечнозелёный лес на планете. Она расположена в азиатской части России. Сибирскую тайгу и лес Амазонки – самый крупный в мире тропический лес, находящийся в Южной Америке, называют «лёгкими планеты», потому что они очищают воздух, которым мы дышим, и выделяют большое количество кислорода для жизни людей и животных.





Яз җитте. Җил һәм Тамчы кабат аланга килделәр. Анда кар эреп бетмәгән иде әле. Анда-санда гына каралып торган урыннар күренә.

– Ә безнең Орлык кайда соң? – дип, тирә-юньгә карандылар алар.

– Мин монда!

Җил яңакларын кабартты һәм өреп җибәрде. Кар эри башлады. Һәм шунда дуслар яшел нарат үсентесен күреп алдылар. Бу Орлык иде.

Наступила весна. Ветерок и Капелька снова прилетели на полянку. На ней ещё лежал снег. Лишь кое-где темнели проталины.

– А где же наша Семечка? – огляделись они вокруг.

– Я здесь!

Ветерок надул щёчки и дунул. Снег начал таять. И тут друзья увидели, что Семечка выросла за зиму и превратилась в зелёную пушистую сосенку.

– Һай, ничек чибәрләнгәнсең син! – дип шатланды Тамчы белән Җил.

– Мин шулай озак йокладыммы? – дип гаҗәпләнде Нарат үсентесе һәм кояшка таба сузылды. – Нишләптер миңа суларга авыр булды.

– Бәлки, сиңа кар комачаулагандыр? – Җил тагын яңакларын кабартты һәм бар көченә өрде. Җылы җил иде ул, һәм алангагы кар тәмам эреп бетте.

– Ах, какой ты стала красавицей! – обрадовались Капелька и Ветерок.

– Я так долго спала! – потянулась к солнышку Сосенка. – Но мне почему-то было очень тяжело дышать.

– Может, тебе мешал снег? – Ветерок снова надул щёчки и изо всех сил дунул. Он был тёплым ветерком, и снег на полянке совсем растаял.



## Ә СИН БЕЛӘСЕҢМЕ? | А ЗНАЕШЬ ЛИ ТЫ?

Кеше бер көнгә 14 килограмм һава сулый. Моның өчен ул 22 мең мәртәбә сулыш ала һәм чыгара.


За день человек вдыхает 14 килограммов воздуха. Для этого он делает 22 тысячи вдохов и выдохов.



## Ә СИН БЕЛӘСЕҢМЕ? | А ЗНАЕШЬ ЛИ ТЫ?

Һава – газлар катнашмасы ул.

Воздух – это смесь разных газов.




Химическая формула

**78 %** – Азот → $N_2$


**21 %** – Кислород → $O_2$

**1 %** – Прочие газы

## БИРЕМ | ЗАДАНИЕ

Елга, парк яки урман янына куярга мөмкин булган плакат уйлап тап һәм яса.

Придумай и нарисуй плакат, который можно было бы поставить у реки, в парке или лесу.



ПЕСЕНКА

КАРАОКЕ

## Ә СИН БЕЛӘСЕҢМЕ? | А ЗНАЕШЬ ЛИ ТЫ?

Уртача алганда, кеше көненә 1 килограмм көнкүреш калдыгы барлыкка китерә. Ә хәзер сезнең йортта яшәүчеләрнең күпме чүп-чар барлыкка китерүен күз алдыңа китереп кара! Ә шәһәрдә яшәүчеләрнең һәммәсе?!

За день человек в среднем производит 1 килограмм отходов. А теперь представь, сколько мусора производят жители дома, в котором ты живёшь! А жители целого города!




## ФАКТ | ФАКТ


Җирдәге чүплекләрнең зурлыгы һәм саны елдан-ел арта. Калдыкларны, чүплекләргә ташлау урынына, кабат эшкәртергә була, моның өчен иң башта аларны сортларга аерырга кирәк.

С каждым годом размеры и количество мусорных свалок растёт. Вместо того чтобы просто выбрасывать мусор на свалку, его можно перерабатывать, а для этого сначала сортировать.




Син табигатькә ярдәм итә аласың! Пластик чүп-чарны аерым чүп савытларына җый, кабат эшкәрткәннән соң, алардан кирәкле һәм файдалы әйберләр җитештерерләр.

Ты можешь помочь природе! Собирай пластиковый мусор в отдельные контейнеры, и тогда после переработки из него сделают много полезных и нужных вещей.



Шунда барысы да аланның чүп-чар белән тулганын күреп алдылар. Менә ни өчен суларга авыр булган икән Нарат үсентесенә.

– Ни булган монда? Каян килгән бу чүп-чар?

– Кешеләр калдырган аны, – дип сүзгә кушылды үтеп баручы эшчән Үрмәкүч.– Алар безнең аланда ял иттеләр. Кемдер үз артыннан җыештырып китте, ә кайберләре чүпне биредә калдырды. Хәзер нишләргә инде безгә?! Алан – безнең йортыбыз һәм үләннәр, чәчәкләр, бөҗәкләр – һәммәсе дә һәлак булырга мөмкин.

Только теперь все увидели, что полянка была покрыта мусором. Вот почему Сосенке было трудно дышать!

– Что произошло? Откуда взялся этот мусор?

– Его оставили люди, – отозвался пробегавший мимо трудяга-Паучок. – Они отдыхали на нашей полянке. Одни убрали за собой мусор, а некоторые оставили его тут. Как нам теперь быть?! Ведь полянка – наш дом. Трава, цветы, жучки и паучки – мы все можем погибнуть!



Кинәт янәшәдә куаклар кыштырдаган, сөйләшкән тавышлар ишетелде. Бу кешеләр иде. Бер гаилә: әти, әни, аларның балалары һәм дуслары аланны чүптән арындырырга килгәннәр.

– Мәрхәмәтле кеше бервакытта да үз артыннан чүп калдырмый, хәтта башкалар калдырганны да җыя. Чөнки ул чүп-чарның җир, һава һәм суларны агулаганын белә.

Вдруг рядом зашевелились ветки кустов, послышались голоса. Это были люди. Семья – папа, мама, их дети и друзья – пришли на полянку для того, чтобы собрать мусор.


– Добрый человек никогда не оставит после себя мусор, а даже уберёт чужой, – улыбнулась Капелька. – Ведь он понимает, что мусор отравляет и землю, и воздух, и воду.





## ФАКТ | ФАКТ

Чүп-чар таркала...
Мусор разлагается за...



| Бумага | Жестяная банка | Пластик | Стекло |
|---|---|---|---|
| **2 года** | **100 лет** | **500 лет** | **1000 лет** |


Чүп-чар табигатьне пычрата. Аның шактые сәламәтлеккә зыянлы. Мондый калдыклар агулы матдәләр бүлеп чыгара, һәм ул суга, туфракка эләгергә мөмкин. Чүп-чар азрак булсын өчен, аларны табигатькә куркыныч тудырмый торган ысул белән чүп яндыру заводларында юк итәләр.

Мусор загрязняет природу. Многие отходы опасны для здоровья. Они выделяют ядовитые вещества, которые могут попасть в землю и воду. Чтобы уменьшить количество мусора, его уничтожают безопасным для природы способом на мусоросжигательных заводах.

## БИРЕМ | ЗАДАНИЕ

Саннар буенча буя: 1 – көрән, 2 – кызгылт-сары, 3 – сары, 4 – яшел, 5 – зәңгәр.

Раскрась по цифрам: 1 – коричневый, 2 – оранжевый, 3 – жёлтый, 4 – зелёный, 5 – голубой.



ИНТЕРАКТИВНЫЕ ИГРЫ

## Ә СИН БЕЛӘСЕҢМЕ? | А ЗНАЕШЬ ЛИ ТЫ?

Кислород – Җирдәге тереклеккә кирәкле иң мөһим газ. Кислородтан башка кеше 2 минут та яши алмый!


Кислород – самый важный и необходимый газ для всего живого на Земле. Без кислорода человек не проживёт и двух минут!





## Ә СИН БЕЛӘСЕҢМЕ? | А ЗНАЕШЬ ЛИ ТЫ?

Бер машина елына 4 мең килограмм кислород яндыра, ә һавага 1,5 мең килограмм газ һәм агулы матдә чыгара!

Одна машина в год сжигает 4 тысячи килограммов кислорода, а выбрасывает в воздух 1,5 тысячи килограммов выхлопных газов, в том числе ядовитые вещества!





– Кайчакларда, бигрәк тә шәһәр өстеннән үткәндә, хәтта миңа да суларга авыр була, – дип кашларын җыерды Җил. – Машиналар шулхәтле күп! Һәм алар һавага пычрак төтен чыгара. Ә хайваннарга, үсемлекләргә һәм кешеләргә сулар өчен чиста һава кирәк!

– Даже мне бывает трудно дышать, особенно когда пролетаю над городом, – насупился Ветерок. – Там много машин! Они выпускают в воздух грязный дым. А чтобы дышать, животным, растениям и людям нужен чистый воздух!



– Әтагын кешеләр зур заводлар һәм электр энергиясе эшләп чыгаручы, суны җылытучы станцияләр төзиләр. Алар өйләрендә якты һәм җылы булсын өчен, электрны – чыбыклар аша, ә суны торбалар буйлап җибәрә. Тик бу станцияләр дә табигатькә зыян китерә, – диде Җил.

– А ещё люди строят большие заводы и станции, на которых добывают электроэнергию, нагревают воду.

Они пускают электричество по проводам, а воду по трубам, чтобы в их домах было тепло и светло, – сказал Ветерок. – Но эти станции тоже наносят вред природе.



## Ә СИН БЕЛӘСЕҢМЕ? | А ЗНАЕШЬ ЛИ ТЫ?

Чүп-чар җирдә озак саклана. Таркалганда, ул туфракны, һаваны, җир асты суларын пычрата һәм тирә-юньгә, кеше сәламәтлегенә зур зыян сала.

Диңгез һәм океаннарга эләккән пластик чүп-чардан һәр ел саен миллионнарча кош, диңгез хайваны һәм балык һәлак була.

Мусор долго сохраняется в земле. Разлагаясь, он отравляет почву, воздух, подземные воды и наносит большой вред окружающей среде и здоровью человека.

Из-за пластикового мусора, который попадает в моря и океаны, погибают миллионы птиц, морских животных, рыб.



Чүп яндыру заводлары ярдәмендә калдыклар кими. Мондый заводлар икеләтә файдалы: чүп-чарны юкка чыгаралар һәм электр энергиясе җитештерәләр.

Мусоросжигательные заводы помогают уменьшить количество мусора. Такие заводы приносят двойную пользу: уничтожают мусор и вырабатывают электроэнергию.


## ТӘҖРИБӘ | ЭКСПЕРИМЕНТ

### СИКЕРҮЧЕ САБЫН КУЫГЫ

1. Йон бияләй ки.
2. Сабын куыгы өреп кабарт һәм аны бияләеңә төшер.
3. Куыкны бияләеңнән өреп төшер һәм аны тагын тот.

### ПРЫГАЮЩИЙ МЫЛЬНЫЙ ПУЗЫРЬ

1. Надень шерстяные варежки.
2. Надуй мыльный пузырь и опусти его на варежку.
3. Сдуй пузырь с варежки и снова поймай его.



ИНТЕРАКТИВНАЯ РАСКРАСКА




## БИРЕМ | ЗАДАНИЕ

Икенчел чимал – иске гәзит һәм журналлардан үзенчәлекле кул эшләнмәсе ясa.
Сделай оригинальную поделку из вторсырья – старых газет или журналов.

**Материаллар: алма, салфетка, гәзит, кылкаләм, кәгазь җилеме яки клейстер, төрле төстәге гуашьлар.**

1. Салфетканы зур булмаган кисәкләргә ерткала һәм юешләп алмага ябыштыр.
2. Иске гәзитне зур булмаган кисәкләргә ерт һәм, җилем сылап, берсе икенчесен яртылаш капларлык итеп ябыштыр. Шулай 3–4 кат ясa.
3. Алманы 1 көнгә киптерергә куй.
4. Эшләнмәне кис һәм алманы ал. Аны кабат салфетка һәм җилем ярдәмендә ябыштыр.
5. Алманы ак төсле гуашь белән буя һәм киптерергә куй.
6. Эшләнмәне буя.


Шул ук алым белән башка яшелчә һәм җиләк-җимеш эшләнмәләре дә ясарга була.




**Материалы: яблоко, салфетка, газета, кисть, клей ПВА или клейстер, гуашь разных цветов.**

1. Нарви салфетку небольшими лоскутами и приклей с помощью воды к поверхности яблока.
2. Нарви старую газету на небольшие кусочки и приклей их с помощью ПВА внахлёст. Сделай 3-4 слоя.
3. Отложи яблоко для высыхания на 1 день.
4. Разрежь поделку и вынь фрукт. Бумажные половинки снова склей с помощью слоя из салфеток и клея.
5. Окрась яблоко белой гуашью и дай высохнуть.
6. Раскрась поделку.

Такие же поделки можно сделать и с помощью других фруктов и овощей.



Ул арада кешеләр аландагы чүпләрне җыеп бетерделәр. Ул кабат яшелләнеп, чистарып калды.

– Хәзер аланга гел киләсе килеп торачак, – диде әти-әнисе һәм абыйсы белән килгән кызчык.

– Ничек әйбәт булды! – дип, ботакларын чәбәкләде Нарат үсентесе. – Алан тирәсендәге урман да тирән итеп сулыш алды!

Кешеләр Нарат үсентесенең сүзләрен ишетмәсәләр дә, аларны шатлык биләп алды. Ә аланда беренче язгы чәчәкләр күренде.

Тем временем люди собрали на полянке весь мусор. Она снова стала чистой и зелёной.

– Теперь следующая поездка на полянку будет приятной, – сказала маленькая девочка, которая пришла вместе с братом, папой и мамой.

– Как хорошо! – захлопала в ладоши-веточки Сосенка. – Даже лес вокруг полянки вздохнул!

И хотя люди не услышали Сосенку, всем стало радостно. А на полянке появились первые весенние цветы.



## ТАБИГАТЬ – БЕЗНЕҢ ЯШЕЛ ЙОРТЫБЫЗ
### СИН ТАБИГАТЬКӘ НИЧЕК ЯРДӘМ ИТӘ АЛАСЫҢ

Чүп-чарны чүп савытына түгел,
әикенчел эшкәртүгә китәрлек итеп аер.




Сортируй мусор, чтобы он отправился
на переработку, а не на свалку.

Электр энергиясен сакла!
Әти-әниеңнән энергияне аз тотучы
лампочка куюларын сора.



Береги электроэнергию!
Попроси родителей поменять лампочки
накаливания на энергосберегающие.

Зарарлы көнкүреш калдыкларын махсус
урыннарга тапшыр.




Сдавай опасные бытовые отходы
в специальные пункты приёма.

Кирәк булмаганда кесә телефоны
чыбыгын розеткадан ал.




Вынимай зарядные устройства из розетки,
когда не пользуешься ими.

Экологик өмәләрдә катнаш.



Принимай участие в экосубботниках.

Кирәк булмаган әйберләреңне тапшыр.





Отдавай ненужные вещи.

ҮЗЕҢӘ ГЕНӘ ТҮГЕЛ, ПЛАНЕТАБЫЗГА ФАЙДА КИТЕРЕРЛЕК ИТЕП ЭШ ИТ!

# ПРИРОДА – ЭТО НАШ ЗЕЛЁНЫЙ ДОМ

## КАК ТЫ МОЖЕШЬ ПОМОЧЬ ПРИРОДЕ

Бер тапкыр кулланыла торган савыт-саба түгел, күп кулланылышлысын сайла.




Используй многоразовую посуду вместо одноразовой.

Пластик пакетлар урынына экологик сумкалар куллан.



Используй экосумку вместо пластиковых пакетов.

Әгәр гаиләгез белән иске кәгазьләрне махсус урыннарга тапшырасыз һәм икенчел чималдан ясалган товарлар (салфетка, туалет кәгазе, киемнәр) сатып аласыз икән, сез бер елга бер агачны коткарып калырсыз.





Если ты вместе с семьёй будешь собирать и сдавать макулатуру в специальные пункты, а также покупать товары, сделанные из вторсырья (салфетки, туалетную бумагу, одежду), то за год вы спасёте целых три дерева.

ПОСТУПАЙ ТАК, ЧТОБЫ ПРИНОСИТЬ ПОЛЬЗУ НЕ ТОЛЬКО СЕБЕ, НО И ВСЕЙ ПЛАНЕТЕ!

Аланда яшәүчеләр һәммәсе дә өйләренең кабат чистаруына шатланды.

– Күрәсеңме, аланда нинди матур чәчәкләр үсеп чыкты, – диде әтиләре. – Әгәр без чүпләрне җыеп алмаган булсак, алар һәлак булырлар иде. Биредә берни үсмәс иде.

– Нишләп кайбер кешеләр чүпне җиргә ташлый? – дип сорады малай әтисеннән.

– Андый кешеләр үзләре яшәгән өйне генә йорт дип уйлый. Тик безнең бердәнбер уртак йортыбыз бар, ул – безнең җиребез, төбәгебез, ватаныбыз.

Все жители полянки радовались, что их дом снова стал чистым.

– Смотри, какие чудесные цветы выросли на этой полянке, – сказал папа. – А если бы мы не убрали здесь мусор, они могли бы погибнуть. Ничего бы здесь не выросло.

– Почему некоторые люди бросают мусор? – спросил мальчик.

– Такие люди думают, что их дом – это только то место, где они живут. Но наш единственный, наш общий дом один на всех – наша земля, наш край, наша родина.





## ФАКТ | ФАКТ


Безнең Татарстаныбыз урманнары белән данлыклы.
Наш Татарстан славится своими лесами.




Чыршы
Ель



Нарат
Сосна



Имән
Дуб



Каен
Берёза

Татарстанда киң таралган ылыслы агачлар: нарат, чыршы, ак чыршы, карагай.

Татарстанда киң таралган яфраклы агачлар: имән, усак, каен, тирәк, өрәңге, юкә.


Распространённые в Татарстане хвойные деревья: сосна, ель, пихта, лиственница.

Распространённые в Татарстане лиственные деревья: дуб, осина, берёза, тополь, клён, липа.


## Ә СИН БЕЛӘСЕҢМЕ? | А ЗНАЕШЬ ЛИ ТЫ?

Агачлар – безнең дусларыбыз. Алар һаваны начар матдәләрдән арындыра, матурлыклары белән сокландыра, җимеш бирә. Агачлар тагын кошлар һәм хайваннар өчен йорт булып тора. Татарстан урманнарында 400 дән артык төрдәге хайван яши.


Деревья – наши друзья. Они очищают воздух от вредных веществ, радуют нас своей красотой, дают плоды. А ещё деревья – это дом для птиц и животных. В лесах Татарстана обитают более 400 видов животных.




Чыршы
Ель



Нарат
Сосна



Имән
Дуб




Каен
Берёза


## ФАКТ | ФАКТ

Бер агач көненә 3 кеше сулый алырлык кислород бүлеп чыгара. Шуңа күрә, агачлар күп үскән җирдә суларга җиңел.

Одно дерево даёт в день столько кислорода, сколько нужно для дыхания 3-х человек. Поэтому нам легко дышится там, где много деревьев.




Химическая формула кислорода



## БИРЕМ | ЗАДАНИЕ

Рәсемне буя!

Раскрась картинку!





– Безнең табигатебез матуррак һәм баерак булсын өчен, без аны сакларга һәм аның турында кайгыртырга тиешбез, – диде әнисе. – Табигатькә чыккач, шаулашырга, агач ботакларын сындырырга, чәчәкләрне өзәргә, хайваннарны һәм кошларны куркытырга, бөҗәкләрне үтерергә, чүп ташларга, учак ягарга ярамый.

Аланда яшәүчеләр бу сүзләрне ишетеп бик шатландылар.

– Чтобы наша природа становилась красивее и богаче, – сказала мама, – нам нужно беречь её и заботиться о ней. На природе нельзя шуметь и ломать ветки, нельзя рвать цветы, пугать животных и убивать насекомых, нельзя разжигать костры и мусорить.

Все жители полянки закивали в ответ. Они были очень рады и благодарны людям.



Кызчык кинәт кенә Нарат үсентесен күреп алды:

– Ай, бигрәк матур! – дип елмайды ул. – Безнең өйдә дә шундый чибәркәй үссә икән!

– Әйдә, аны зур чүлмәккә утыртып, өйдә үстерик. Яңа елга үз агачыбыз булыр, – дип тәкъдим итте кызның абыйсы. – Без аны карап үстерербез, бәйрәмгә ел саен бизәрбез.

– Нарат үсентесенә шәһәрдә күңелсез булыр, – диде әнисе. – Аның өе дә, дуслары да биредә.

Вдруг девочка заметила Сосенку:

– Ах, какая хорошенькая! – улыбнулась она. – Вот бы нам такую красавицу домой!

– Давай посадим её дома в большой горшок. Будет у нас своё новогоднее деревце, – придумал брат девочки. – Будем о ней заботиться и каждый год наряжать на праздник.

– Сосенке будет скучно в городе, – сказала мама. – Здесь её дом и друзья.






## БИРЕМ | ЗАДАНИЕ

Нарат – Татарстанда иң киң таралган агачларның берсе. Ул комлы туфракта да, тау битләрендә дә үсә. Ул кояш нурларын ярата.

Сосна – одно из самых распространённых деревьев в Татарстане. Она может расти даже в песке и на скалах. Сосна очень любит солнышко.






## Ә СИН БЕЛӘСЕҢМЕ? | А ЗНАЕШЬ ЛИ ТЫ?

Үтә күренмәле алтынсу таш – гәрәбә, башка кыйммәтле ташлар кебек, җирдә барлыкка килми. Гәрәбә – борынгы ылыслы агачларның ташка әйләнгән сумаласы ул.

Янтарь – прозрачные золотистые камешки – рождаются вовсе не в земле, как другие драгоценные камни. Янтарь – это окаменевшая смола древних хвойных деревьев.



ИНТЕРАКТИВНЫЕ ИГРЫ



## ФАКТ | ФАКТ


Нарат ылысының энәләре икешәр-икешәр.

У сосны сдвоенные хвоинки.





## БИРЕМ | ЗАДАНИЕ

Ребусны чиш!



| | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | | |

Разгадай ребус!




| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | |





Тик балалар әниләрен тыңламадылар. Нарат үсентесе аңламыйча да калды – алар аны зур сумкага салып та куйдылар.

Өйгә кайткач, балалар Нарат үсентесен чүлмәккә утырттылар.

– Сиңа монда җылы һәм уңайлы булыр, – дип, ягымлы итеп эндәште кызчык.

Тик үсентене матур чүлмәк тә, кызның сүзләре дә, аңа су сибүе һәм төбен йомшартуы да шатландырмады.

Ул аланны һәм дусларын сагынды. Аның энәләре көннән-көн тоныклана барды һәм саргайды.

Но ребята не послушались мамы, и не успела Сосенка ахнуть, как они уложили её в большую сумку.

Приехав домой, дети посадили Сосенку в горшочек.

– Здесь тебе будет и теплее, и уютнее, – ласково сказала девочка.

Но Сосенку не радовал ни красивый горшочек, ни то, что девочка поливала её и рыхлила землю.

Сосенка скучала по своим друзьям и полянке. С каждым днём её хвоинки тускнели и желтели.



– Мескен Нарат үсентесе, нишләп шундый моңсу син? – дип борчылды кызчык.

– Ул үзенең дусларын сагына. Сез, мине тыңламыйча, аны үсеп утырган аланыннан алып киттегез. Хәзер ул һәлак булырга мөмкин.

– Без Нарат үсентесенең һәлак булуын теләмибез, – дип елап җибәрде балалар. – Нишләргә инде безгә хәзер?

– Бедная Сосенка! – расстроилась девочка. – Почему ты такая грустная?


– Она скучает по своим друзьям. Вы не послушались и увезли её с полянки, где она выросла. И теперь она может даже погибнуть.

– Мы не хотим, чтобы Сосенка погибла, – заплакали дети. – Что же нам делать?


## Ә СИН БЕЛӘСЕҢМЕ? | А ЗНАЕШЬ ЛИ ТЫ?

Кәгазь агачлардан җитештерелә. Шуңа күрә агачларны сакларга, яңаларын утыртырга кирәк!

Бумага производится из срубленных деревьев. Поэтому нужно беречь деревья и сажать новые!




ИКЕНЧЕЛ ЧИМАЛДАН БУЛГАН КӘГАЗЬ АЛЫГЫЗ!
ПОКУПАЙТЕ БУМАГУ ИЗ ВТОРСЫРЬЯ!



МАКУЛАТУРА ТАПШЫРЫГЫЗ!
СДАВАЙТЕ МАКУЛАТУРУ НА ПЕРЕРАБОТКУ!



КӘГАЗЬНЕ ӘРӘМ-ШӘРӘМ ИТМӘГЕЗ!
НЕ ТРАТЬТЕ БУМАГУ ЗРЯ!




АГАЧЛАР УТЫРТЫГЫЗ!
САЖАЙТЕ ДЕРЕВЬЯ!

ПЕСЕНКА
КАРАОКЕ

## ФАКТ | ФАКТ

Нарат йөзләрчә ел яши. Ә Җирдәге иң карт Мафусаил наратының яше – 5 мең ел тирәсе. Ул Мисыр пирамидаларыннан күпкә алданрак үсеп чыккан.


Сосны – долгожители. Они живут сотни лет. А самой старой сосне на Земле – сосне Мафусаил – около 5 тысяч лет! Она стояла задолго до появления египетских пирамид.



## Ә СИН БЕЛӘСЕҢМЕ? | А ЗНАЕШЬ ЛИ ТЫ?

Агачлар шәһәрдәге шау-шуны киметә. Ә наратлар үзенчәлекле, сәламәтлеккә бик тә файдалы булган матдәләр – фитонцидлар бүлеп чыгара.

Деревья уменьшают уровень шума в городе. А сосны ещё и выделяют особые, очень полезные для здоровья вещества – фитонциды.





– Аңа кояш нурлары җитмидер, – диде әтиләре. – Әйдәгез, аны мәктәп ишегалдына алып барыйк һәм башка агачлар янына утыртыйк.

Балалар шатланыштылар һәм, Нарат үсентесе утыртылган чүлмәкне алып, мәктәпкә киттеләр.

– Наверное, ей не хватает солнышка, – сказал папа. – Давайте отнесём её на школьный двор и посадим рядом с другими деревьями.

Дети обрадовались, взяли горшочек с Сосенкой и пошли к школе.



Әтиләре чокыр казыды, әниләре сак кына Нарат үсентесен утыртты. Ә балалар аның ботакларын рәтләп куйдылар.

Нарат үсентесе матурланып, кабарып китте.

– Нарат үсентесе, син чын сәяхәтче, – дип көлеште дуслары – Тамчы белән Җил.


Папа выкопал ямку, мама заботливо посадила Сосенку. А дети расправили её веточки.


Сосенка стала ещё красивее и пушистее, чем прежде.

– Сосенка, ты настоящая путешественница! – смеялись её друзья – Капелька и Ветерок.










## ЖИР СӘГАТЕ
## ЧАС ЗЕМЛИ

Ел саен мартның соңгы шимбәсендә җир йөзендәге күп кешеләр, Җир ял итсен һәм кабат көч җыйсын өчен, 1 сәгатькә өйләрендәге утларын сүндереп торалар. Әлеге акциядә гаиләң һәм дусларың белән син дә катнаш! **ҖИРЕБЕЗНЕ САКЛА!**

Каждый год в последнюю субботу марта многие люди во всём мире на 1 час выключают свет в своих домах, чтобы Земля могла отдохнуть и набраться сил. Участвуй в акции вместе с семьёй и друзьями! **БЕРЕГИ НАШУ ЗЕМЛЮ!**

### БИРЕМ | ЗАДАНИЕ

Хәрефләрдән сүз төзе.
Собери из букв слово.

| Г | А | Т | А | Б | И | Т | Ь |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | | |

| Л | О | Э | К | О | Я | И | Г |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | | |

# ЯҢА АГАЧКА ГОМЕР БҮЛӘК ИТ!

## КАДЕРЛЕ ДУСТЫМ!

Син дә, әкият геройлары кебек үк, гаиләң белән бергә агач утырта аласың. Гаилә агачы синең белән бергә үсәчәк һәм барыгызны да үзенең матурлыгы белән сөендереп торачак!

Мәсәлән, нарат яки чыршы утырту өчен, күркәдән берничә орлык ал. Алмагачны – алма орлыгыннан, ә имәнне имән чикләвегеннән үстерергә мөмкин.

# ПОДАРИ ЖИЗНЬ НОВОМУ ДЕРЕВУ!

## ДОРОГОЙ ДРУГ!

Ты тоже, как и герои сказки, можешь посадить вместе со своей семьёй дерево. Семейное дерево будет расти вместе с тобой и радовать всех своей красотой!

Чтобы посадить, например, сосну или ель, возьми несколько семечек из шишки. Яблоню можно вырастить из яблочного семечка, а дуб – из жёлудя.

1 Кечкенә генә дымлы мамык мендәре куелган чәй тәлинкәсенә берничә орлык сал һәм аларны шул ук мамык белән яхшылап каплап куй.
Положи несколько семечек в блюдечко на подушечку из влажной ваты и хорошенько прикрой сверху той же ватой.





2 Дым парга әйләнмәсен өчен, тәлинкәне полиэтилен пакет белән капла һәм суыткычка куй.
Чтобы влага не испарялась, закрой блюдечко полиэтиленовым пакетом и поставь в холодильник.



3 Ай дәвамында атна саен, пакетны ачып, орлыкларны җилләтеп ал.
Каждую неделю в течение месяца открывай пакет и проветривай семечки.




4 Бер айдан соң үргән орлыкларның тамырлары үсә башлар. 3–5 орлыкны, бер-берсеннән аз гына ара калдырып, 1 см тирәнлектә чүлмәккә утырт һәм тондырылган су сип. Орлыклы чүлмәкне җылы урынга куй (18–25 °С).

Через месяц у проросших семечек начнут расти корешки. Посади 3–5 семечек в горшочек на глубину 1 см, на небольшом расстоянии друг от друга и полей отстоянной водой. Поставь горшочек с семенами в тёплое место (18–25 °С).

5 Чәчкеннәр бер айдан шытып чыгар. Чүлмәктәге туфрак һәрвакыт бераз дымлы булырга тиеш, моны тикшереп тор. Булачак агачны фотога төшерергә онытма.

Сеянцы взойдут через месяц. Следи за тем, чтобы земля в горшочке всегда была чуть влажной. Не забывай фотографировать будущее деревце.






6 Бер елдан иң көчле үсентеләр 5–15 см га үсәчәк! Үзләре үскән туфрагы белән бергә аларны даими урынга күчереп утырт.

Через год самые сильные саженцы вырастут на 5–15 см! Высади их вместе с комом земли, в котором они росли, на постоянное место.

Агачың турында кайгыртып тор, һәм ул бик күп еллар синең белән бергә матур агач булып үсәчәк.

Заботься о своём деревце, и оно вырастет в прекрасное дерево, которое будет расти вместе с тобой много лет.

Руководитель и соавтор проекта
**Лейла Фазлеева**

Продюсеры проекта
**Светлана Котенкова, Азат Ганиев**

Автор и главный редактор
**Гульнара Головина**

Перевод
**Фансии Сафиной, Зухры Фасхиевой**

Литературная редакция:
**Алсу Низамеева, Гюльнара Фазлиахметова, Инна Макарова,
Фансия Сафина, Зухра Фасхиева, Фарида Ахметзянова**

Дизайн и компьютерная вёрстка
**Дмитрия Гиацинтова**

Автор персонажей
**Аида Ромашова**

Художники-иллюстраторы:
**Аида Ромашова, Светлана Масальских,
Арина Карпова, Анна Гаранина, Захар Мигунов**

Авторская музыка
**Марии Сергеевой**

Музыкальный редактор и звукорежиссёр
**Рафаэль Бахтиозин**

Стихи
**Фансии Сафиной, Марии Сергеевой, Инны Макаровой**

Руководитель IT отдела
**Дамир Бариев**

Технический директор
**Ильдар Низаметдинов**

Методисты:
**Эльмира Тахавиева, Лейсан Зинатуллина, Татьяна Курамшина**

Консультанты:
**Расима Шамсутдинова, Дмитрий Иванов, Марат Фасхутдинов**

Проект осуществлён при консультационной поддержке
Министерства экологии Республики Татарстан

**Татарское детское издательство**
**Редакция Гульнары Головиной**

420124, г. Казань, ул. Сулеймановой, 5.
www.tdpress.ru

Подписано в печать 26.07.2021.
Печать офсетная. Тираж 60 000 экз. Заказ № 22813.
196643, Россия, Санкт-Петербург, Колпинский р-н,
пос. Сапёрный, ш. Петрозаводское д. 61, стр. 6
Тел. (812) 462-83-83, e-mail: office@ldprint.ru

# Ылыслы әкият | Хвойная сказка


Дусларның әкияти маҗаралары | Сказочные приключения друзей



www.хвойнаясказка.рф

Дусларым! Чүпләрне сортларга аерып, сез аларның әйләнә-тирәгә начар йогынтысын киметәсез һәм кайбер әйберләргә икенче тормыш бүләк итәсез. Бу белешмәлек сезне чүп-чарны дөрес итеп сортларга аерырга өйрәтер һәм эш барышын җиңеләйтер.

## ПЛАСТИК




## НУЖНО УТИЛИЗИРОВАТЬ



ПЭТ-БУТЫЛКИ



ПАКЕТЫ, МЕШКИ



ДОМАШНЮЮ УТВАРЬ




БУТЫЛКИ БЫТОВОЙ ХИМИИ, КОСМЕТИКИ

## БУМАГА




## НУЖНО УТИЛИЗИРОВАТЬ




КАРТОННЫЕ КОРОБКИ



БУМАЖНЫЕ ПАКЕТЫ



ТЕТРАДИ, БУМАГУ



КНИГИ, ГАЗЕТЫ, ЖУРНАЛЫ

## КУРКЫНЫЧ КӨНКҮРЕШ КАЛДЫКЛАРЫН
### МАХСУС КАБУЛ ИТҮ ПУНКТЛАРЫНА ГЫНА ТАПШЫРЫГЫЗ!

- Батарейкалар һәм аккумуляторлар
- Терекөмешле градусниклар
- Санаклар, электрон җиһазлар
- Яктырткычлар
- Аэрозольдән бушаган савытлар
- Кулланылу вакыты чыккан дарулар
- Буяу, лак, җилем калдыклары

Друзья! Сортируя мусор, вы уменьшаете вредное влияние отходов на окружающую среду и даёте некоторым ненужным вещам вторую жизнь. Эта памятка поможет вам научиться сортировать мусор правильно и сделает этот процесс проще и приятнее.

## ПЛАСТИК




### НЕЛЬЗЯ УТИЛИЗИРОВАТЬ



**УПАКОВКУ**
ИЗ-ПОД КЕТЧУПА, МАЙОНЕЗА, КОФЕ



**УПАКОВКУ ОТ ЧИПСОВ**



**ТУБЫ ОТ ЗУБНОЙ ПАСТЫ**




**КАНЦЕЛЯРСКИЕ ИЗДЕЛИЯ**


## БУМАГА




### НЕЛЬЗЯ УТИЛИЗИРОВАТЬ



**ФОТОГРАФИИ**



**УПАКОВКУ,**
ЗАГРЯЗНЁННУЮ ПИЩЕЙ



**УПАКОВКУ**
ИЗ-ПОД СОКА, МОЛОКА



**ОБОИ**

## ОПАСНЫЕ БЫТОВЫЕ ОТХОДЫ

### СДАВАЙТЕ ТОЛЬКО В СПЕЦИАЛЬНЫЕ ПУНКТЫ ПРИЁМА!

- Батарейки и аккумуляторы
- Ртутные градусники
- Компьютеры, электроника
- Лампы
- Аэрозольные флаконы
- Неиспользованные лекарства
- Остатки краски, лака и клея



ТОИ
ЭМОЦИОНАЛЬНЫЙ ИНТЕЛЛЕКТ
ТАТАРСКОЕ ДЕТСКОЕ ИЗДАТЕЛЬСТВО • ТАТАР БАЛАЛАР НӘШРИЯТЫ
www.tatbook.ru

www.хвойнаясказка.рф

ISBN 978-5-6043753-6-5
9 785604 375365